Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

11.09.2023 ел Менделеевск ш. №210

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
территориаль планлаштыру схемасына
үзгәрешләр кертү проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьяларына, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына 2022 елның 21 августындагы 10-53/10177 нәтиҗәсе нигезендә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2022 елның 12 августындагы 131 карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын түбәндәге торак пунктлар чикләре турында мәгълүмат белән тулыландыру өлешендә расларга:

- Бөрешле авылы, Бөрешле авыл җирлеге чикләрендә урнашкан;
- Ижевка авылы, Ижевка авыл җирлеге чикләрендә урнашкан.

Югарыда санап үтелгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашканнарга карата генераль план әзерләү кирәкми.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга www.mendsleevsk.tatar.ru, расланган документны Россия Федерациясенең территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2022 елның 12 августындагы 131 карары үз көчен югалткан дип саналырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Менделеевск муниципаль районы Советының икътисад, сәнәгать, торак-коммуналь хуҗалык, төзелеш һәм элемтә мәсьәләләре буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе Р.И.Беляев